ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ТАКТАЛАЧЫК
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

423751, Такталачык авылы, Г.Авзал урамы,
48 йорт, тел.3-44-57

СОВЕТ
ТАКТАЛАЧУКСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

423751, село Такталачук, ул. Г.Авзал,
дом 48,тел.3-44-57

КАРАР | РЕШЕНИЕ

от 24.11.2020 г. №27

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, "Такталачык авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 25.1 статьясы нигезендә Актаныш муниципаль районы, Такталачык авыл җирлеге Башлыгы:

Карар бирә:

1. 2021 елда 18 яшькә җиткән, яшәү урыны җирлек чикләрендә теркәлгән һәр гражданнан 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертүгә, 1 төркем инвалидлардан,көндезге формада белем алучы студентлардан кала, алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү турында:

1. Ритуаль хезмәтләрне оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту:
- агачлар кисү, территорияне төзекләндерү;
2. Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:
- су белән тәэмин итү системасын төзекләндерү, карап тору, лицензияләү;
3. Атомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
- юлларны карап тоту, төзекләндерү, щебень, ком салу, кардан чистарту, тигезләү;
4. Җирлек халкының массакүләм ял итү өчен шартлар тудыру:
- физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт, массакүләм чаралар оештыру һәм уздыру;
5. Җирлек территориясендә төзекләндерү эшләрен оештыру;
- авыл җирлеге территориясендәге агачларны кисү;
- Сабантуй үткәрү урыннарын төзекләндерү;
- хуҗасыз йортларны һәм биналарны бетерү;
- урам исемнәре һәм йорт номерлары белән күрсәткечләр урнаштыру;
- урам утларын урнаштыру, карап тору;
- декларация алдыннан ГТСны тикшерү;

2. Актаныш муниципаль районы Такталачык авыл җирлеге гражданнарының халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштырырга

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында игълан итәргә

Такталачык авыл җирлеге советына
рэислек итуче М.Т.Мансуров